ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«04 » август 2021 ел № 110-р

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» республика хәйрия акциясе кысаларында җыелган акчаларны бүлү комиссиясен раслау турында**

«Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» республика хәйрия акциясе турында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2021 елның 12 июлендәге 8576/21 номерлы хаты нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2021 елга түбәндәге составта «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» республика хәйрия акциясе кысаларында җыелган акчаларны бүлү комиссиясен расларга:

- Баженова Ольга Алексеевна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе;

- Сафиуллина Вәсилә Гарәфетдин кызы - «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары;

- Зиновьева Ландыш Ильфар кызы – «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең баш белгече-юристы, комиссия әгъзасы;

- Зиннәтова Нажия Мөхәммәтнур кызы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге советы депутаты, комиссия әгъзасы;

- Яппарова Лилия Дөфар кызы – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең «Бәләкәч» 7 нче балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире, комиссия әгъзасы.

2. Мәгариф комиссиясе «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» республика хәйрия акциясе кысаларында җыелган акчаларны бүлү эшен 2021 елның 13 августына кадәр төгәлләргә

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгына 2021 елның 5 августына кадәр хәйрия ярдәменә мохтаҗ балалар исемлекләрен килештерергә.

4. «Мәктәп портфелен» тантаналы тапшыру чарасын 2021 елның 20 августында 11.00 сәгатьтә Әгерҗе шәһәре, Чайковский ур., 15 йорт адресы буенча «Талантлар салават күпере» базасында үткәрергә.

5. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **О.А. Баженова**